Литература

Арутюнова, Н.Д. Язык и мир человека. / Н.Д. Арутюнова. – 2-е изд., исп. – М.: «Языки русской культуры», 1999. – 896.

Исәнбәт, Н. Татар халык табышмаклары. – Казан, 1970. – 568 б.

Мәхмүтов, Х.Ш. Борынгылар әйткән сүзләр / Х.Ш. Мәхмүтов. – Казан, 2002. – 175 б.

Татар халык иҗаты. Табышмаклар. – Казан, 1977. – 231 б.

Гаязов Нур Илгизарович

Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан

ХХ ГАСЫР БАШЛАРЫ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ ТЕЛ-СТИЛЬ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ (Г. ТУКАЙ ҺӘМ М. ГАФУРИ ӘСӘРЛӘРЕ МИСАЛЫНДА)

Статья посвящена сопоставительному изучению лингвистических особенностей творчества двух выдающихся татарских поэтов – Габдуллы Тукая и Мазита Гафури. Язык произведений, творчество в целом и даже жизнь этих личностей очень схожа. В связи с этим вопрос сопоставительного изучения языковых особенностей произведений поэтов является актуальным исследованием в области лингвистики.

Ключевые слова: *Татарская литература XX века, изучение языка произведений Г. Тукая, стиль М. Гафури, взаимодействие литературы, сравнительный анализ.*

This article is devoted to the comparative analysis of linguistic features of creativity of G. Tykai and M. Gafuri. These poets are outstanding representatives of the Tatar literature of the early XX century. Language of compositions, creation in general, and even the lives of these individuals are very similar. In connection with this the question of the comparative studying of linguistic features of poems of the poets is an actual investigation in the field of linguistics.

Key words: *Tatar literature of the 20th century,The study of the language of the writing of G. Tukai, the Style Of The M. Gafuri, the interaction of literature, training in comparative plan.*

XX гасыр башында татар әдәбияты үзенең яңа дәвергә аяк баса. Аның шушы үсеш баскычларын яңа буын шагыйрьләре – Габдулла Тукай һәм Мәҗит Гафурилар билгели. Г. Тукай һәм М. Гафури бу еллар татар әдәбиятын үстерүгә үзләреннән зур өлеш кертәләр. Берсе – Казанда, икенчесе – Уфада татар милләтенең зәвыгын үстерүгә, үзаңын уяту юлында армый-талмый халыкка хезмәт итәләр.

Г. Тукай һәм М. Гафури арасында охшаш яклар бик күп. Бу, әлбәттә, аларның тормыш юлларында да, шулай ук иҗатларында да һәм хәтта, әдәби

әсәрләренең телендә дә чагылыш таба. Тормышларына күз салсак, икесе дә бик яшьли ятим калалар, тормышның барлык кыенлыкларын күреп, тоеп үсәләр. Бик яшьли тормыш сынауларына дучар булалар. Әлеге кыенлыклар аларның әсәрләрендә бик киң планда яктыртыла. Мәсәлән, Г. Тукайның «Исемдә калганнар» һәм М. Гафуриның «Тәрҗемәи хәлем», «Баштан үткәннәр», «Шагыйрьнең алтын приискасында» кебек чәчмә әсәрләре шундыйлардан. Әлеге тасвирлауга корылган автобиографик әсәрләрнең теле һәм стиле дә охшаш: авторлар әсәрләрен алынмалардан максималь рәвештә арындырып, саф әдәби татар телендә язарга омтылганнар. Мисалларда бу ачык күренә. Чагыштырып карыйк:

Азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим?!
Азрак үстерде сыйпап тик маңлаемнан милләтем...

[Г. Тукай «Дошманнар»]

Ата-анадан мәхрүм булып, калдык ятим,
Шулай да башкалардан булмадык ким.
Бу дөнья ни күрсәтмәс ир кешегә!
Һич зыян юк, әгәр булса күкерәк киң.

[М. Гафури «Яшь гомерем»]

Күрүебезчә, М. Гафурига һәм аның поэтик өслүбенә Г. Тукай әсәрләре, алардагы миллилек, халыкчанлык идеяләре бик нык тәэсир иткән. Бу очракта аларның икесенә дә Г. Исхакый ясаган йогынтыны да онытырга ярамый. Тукайның Гафури иҗатына ясаган тәэсирен без иң элек әсәрләрдәге тематикадан һәм тел-стиль үзенчәлекләреннән күрәбез. Чыннан да, бер-берсен хәтерләткән шигъри охшашлыкларны бу ике әдип иҗатында табып алуы кыен түгел. Бу уртаклык, бу аваздашлык, тасвирлау детальләре, сурәтләү рәвеше һәм образлар системасына да үтеп керә.

Нигә, дим, изге мәктәптән, *сабый чактан айрылдым*?
Нигә мин кечкенә Апуш түгел, *зуп-зур Тукай булдым*?

[Г. Тукай «Гомер юлына керүчеләргә»]

Минем *гомрем* минутлары менә шул тамчылар төсле;
Ага шул су кебек яки эри яз көнге кар төсле.

[М. Гафури «Үтә гомерем»]

Беренче рус революциясеннән соң Гафури поэзиясендә Тукайдагы кебек үк революция-азатлык темасы бик ныклы урын ала. Аның төрле төсмерләре, аспектлары, юнәлешләре барлыкка килә. Үзләренең иҗат кыйблаларын халыкка төбәгән шагыйрьләрнең иң алдынгы сафында торып, Тукай һәм Гафури, бертавыштан халыкка бетмәс ышаныч белән тулы декларацияләрен игълан итәләр [5: 267]. «Дөресен әйткәндә, халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул», – дип чыкты Тукай 1910 нчы елда «Халык әдәбияты» дигән лекциясендә һәм М. Гафури 1911 нче елда «Халык теләге» дигән мәкаләсендә, әйтерсең, Тукай фикерләрен уртаклашып

һәм дәвам иттереп: «Халык теләгенең көчле вә куәтле булуында шөбһә юктыр... Халык теләге – һәр нәрсәне булдыра ала торган бер куәттер. Бары тик халыкта бу теләү хисе кузгалсын гына...» – диде һәм халыкка үз хокукларын яулап алу өчен көрәш теләгенең һич сүнмәгәнлегенә тирән ышаныч белдерде [2]. Күрүебезчә, әдипләрнең хәтта публицистик стилендә дә охшашлыклар бар. Бу, әлбәттә, шагыйрьләрнең идея-эстетик карашларыннан чыгып, бер үк фикердә яшәүләре белән тыгыз рәвештә бәйле. Идеяләр бер үк булганда, бу телдә дә чагылыш таба [6].

Г. Тукай һәм М. Гафури балалар әдәбиятын үстерүгә дә үзләреннән зур өлеш кертәләр. Алар балалар әдәбиятын яңа әкиятләр, шигырьләр, хикәяләр, мәсәлләр һәм поэмалар белән баеталар. Бу, әлбәттә, татар балалар әдәбиятын яңа баскычка күтәрү була. Әдипләрнең балалар өчен язылган әсәрләренең теле таң калдыра: ул кечкенә баланың игътибарын җәлеп итеп, аңа аңлаешлы итеп мавыктыргыч вакыйганы сурәтләүгә корылган. Гафури Тукай тудырган профессиональ татар балалар поэзиясе телен яңа чорда, яңа иҗтимагый үсеш баскычына алып китә. Бигрәк тә Тукай вафатыннан соң, Гафури аның традицияләрен дәвам иттерә һәм үстерә.

Шунысын да әйтеп узарга кирәк, М. Гафури татар поэзиясендә мәсәл жанрын тернәкләндерә, аңа яшәү көче бирә, аны шигъриятебезнең үсеш юлына алып чыга. Әлеге мәсәлләр тематик яктан төрле: кош-кортлар, җанварлар арасындагы мөнәсәбәтләргә корылган («Ике каз белән бака», «Ат белән эт»), төрле җәнлек һәм хайваннар, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне чагылдыра («Бабай белән аю», «Бай белән хезмәтче»). Бу мәсәлләр балалар әдәбиятының уңышлы әсәрләре булып кабул ителделәр.

Г. Тукай һәм М. Гафури – классик стиль, традицион шигырь тарафдарлары. Алай гына да түгел, алар үзләре шушы XX гасыр башында яңарган шигъри стильне тудыручыларның берсе. Атаклы француз язучысы Луи Арагон хаклы рәвештә болай дип яза: «Тукай һәм Гафури поэзияләре, Ибраһимов романнары татар совет язучыларына юл хәзерләде...» [3: 65] Г. Тукай һәм М. Гафури татар әдәбиятын һәм милли телен үстерүдә генә түгел, ә тугандаш халыклар һәм хәтта чит ил әдәбиятларында да тәрҗемә ителеп, халык тарафыннан яратылып укылып, зур ихтирамга лаек булалар. Мәсәлән, үзбәк шагыйре Хәмзә, казакъ Омар әлеге әдипләребезнең иҗатларын ярату турында язалар. Казакъ, кыргыз, үзбәк, чуваш һ.б. халыклар аларның әсәрләрен күптән инде үз телләрендә укыйлар, шуңа күрә шигырь-поэмаларының тәэсирен ныграк тоялар.

Әдәбият

1. Гафури, М. Әсәрләр: Дүрт томда / М. Гафури. – Казан: Татар. кит. нәшр. – I т. – 1980; II т. – 1980; III т. – 1983; IV т. – 1981.
2. Гафури, М. Халык теләге / М. Гафури // Вакыт. – 1911. – 13 гыйнвар.

3. Нигъмәтҗанова, А. Чит илдәге милләттәшләр һәм Тукайның иҗат мирасы / А. Нигъмәтҗанова // Мәгариф. – 1993. – №8. – Б.25.
4. Нуруллин, И. З. XX йөз башы татар әдәбияты. [Урта мәктәп укучылары, студентлар һәм югары класс укучылары өчен дәреслек-кулланма]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – 286 б.
5. Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. – IV т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 568 б.
6. Шакурова, М.М. Лингвистический анализ фольклорного текста (на материале сказок и баитов) / М.М. Шакурова // Филология и культура. Philology and culture. 2014. №4(38). – С. 216-220

Гиниятуллина Лилия Миннуловна
Айдарова Светлана Ханиповна
Казанский (Приволжский) федеральный университет, Казань

ПРИДАТОЧНЫЕ ПОДЛЕЖАЩНЫЕ И СКАЗУЕМНЫЕ В УЧЕБНИКАХ ПЕРВОЙ ПОЛОВИНЫ XX ВЕКА

Данная статья посвящена исследованию формирования в татарском языкознании сложноподчиненных предложений с придаточными подлежащными и сказуемными. Подробный анализ учебников начала и середины прошлого столетия позволит иметь представление об историческом развитии синтаксиса сложного предложения в целом.

Ключевые слова: *татарский язык, синтаксис, придаточное предложение.*

This article is devoted to the study of the formation of complex sentences with subject and predicative clauses in the Tatar linguistics. A detailed analysis of the textbooks of the beginning and the middle of the last century, will allow an understanding of the historical development of the syntax of a complex sentence as a whole.

Key words: *Tatar language, syntax, subordinate clause*

Вопрос типологии сложноподчиненных предложений – один из наиболее сложных вопросов. «Проблема спецификации сложноподчиненных предложений является одной из наиболее спорных в научных описательных грамматиках тюркских языков. Еще до лингвистической дискуссии 1950 г. шел спор о природе причастных и деепричастных оборотов. Некоторые языковеды считали, что все без исключения причастные и деепричастные обороты являются придаточными предложениями. Другие в противовес первому мнению полагали, что эти обороты являются придаточным предложением только в том случае, если они имеют своё собственное подлежащее, отличное от подлежащего главного предложения». [Ширалиев, 1956: 93]